КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 апрель г.Казань № 502

Төзелеш тармагында эшләүче беренче разрядлы эшченең уртача айлык хезмәте өчен түләү күләме турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзелеш ресурслары бәяләрен мониторинглау турында» 2016 елның 23 декабрендәге $145^2$ номерлы карары белән расланган Төзелеш ресурслары бәяләрен мониторинглау кагыйдәләренең 221 нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклап калу эшләренең, капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең, капиталь ремонтлауның, җимерүнең смета кыйммәтен билгеләү максатларында төзелеш тармагында эшләүче беренче разрядлы эшченең уртача айлык хезмәте өчен түләү күләмен 2022 елга 28 751,9 сумга тигез итеп билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеш тармагында мәшгуль булган беренче разрядлы эшче хезмәте өчен түләүнең уртача айлык күләме турында» 2022 ел, 27 май, 491 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин